*Хатыйп Миңнегулов*

# Хатип Госманның Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятын өйрәнү өлкәсендәге эшчәнлеге

Иң әүвәл шәхси эчтәлектәге берничә сүз әйтергә җөрьәт итәм. Мин 1959 елда Казан университетына укырга кердем. Шул вакыттан бирле, ягъни ярты гасырдан артык минем гомер юлы шушы уку йорты белән бәйле. Тормышта төрле кыенлыклар, күңелсезлекләр булып торса да, мөгаллим-остазлар ягыннан мин бик тә уңдым: Хатип Госман, Ибраһим Нуруллин, Нил Юзиев, Зәет Мәҗитов, Мансур Хәсәнов, Мирфатыйх Зәкиев, Диларә Тумашева, Әнвәр Әфләтунов, Рәфыйк Нәфыйков, Җәвад Алмаз һ.б. Болар (барысы диярлек – ир-атлар!) галимнәр, (“учебный”) предмет (“фән”) ияләре генә түгел, ә милләт язмышы, аның теле, әдәбияты өчен янып-көюче олуг шәхесләр, җәмәгать эшлеклеләре дә иде. Кызганыч, андый затлар хәзер бик азаеп, үз фәне кысаларыннан читкә китмәгән предмет ияләре күбәеп китте. Бүгенге көндә татарның милләт буларак язмышы, теле, мәдәнияте, гомумән бөтен барлыгы кыл өстендә. Мондый шартларда исә татарның һәр мөгаллиме, гыйлем иясе, әдибе, сәнгать әһеле, журналисты үз өлкәсенең белгече генә түгел, ә үз халкының яшәеше, мәнфәгатьләре өчен фидакарьләрчә көрәшүче дә булырга тиеш. Безнең остазларыбыз мондый юлда безгә үрнәк, өлге булып тора.

* * *

Миңа инде Х.Госманның (1908 - 1992) тормышы, эшчәнлеге хакында берничә мәкалә язарга, хәтта бер китапчык та [1] чыгарырга туры килгән иде. Аның турында Н.Юзиев, Н.Хисамов, Р.Ягъфәров, А.Яхин һәм кайбер башка каләм әһелләренең дә язмалары бар[1, 15-16]. Аларда бу олуг галимнең шәхесе, күпкырлы эш-гамәлләре шактый чагылыш таба. Биредә исә без бу мөхтәрәм затның Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятын өйрәнүдәге эшчәнлеге хакында гына сүз алып барырбыз.

Х. Госманның элеккеге сүз сәнгате белән кызыксына башлавы узган гасырның урталарына туры килә. Мәгълүм ки, 1956, 1957 елларда татар һәм

урыс телләрендә “Татар поэзиясе антологиясе” дөнья күрә. Аларга кереш сүз рәвешендә язылган мәкаләдә Х.Госман татар шигъриятенең Мәхмүд Кашгарый китабындагы парчалардан, Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәреннән башлануын искәртә, Котб, Харәзми, С.Сараи, Мөхәммәдьяр, Мәүла Колый, Утыз Имәни кебек авторларның да исемнәрен, әсәрләрен телгә ала.

Әмма Х.Госманның борынгы язма мирас белән ныклап шөгыльләнә башлавы 50 нче елларның ахырына – 60 нчы елларга туры килә. Һәм гомумән бу юнәлеш галим эшчәнлегенең соңгы чорына кадәр дәвам итте.

Х. Госман төп игътибарын борыннан да элек язма әдәбиятның туу һәм үсү шартларын ачыклауга юнәлтә. Аның фикеренчә, язма сүз сәнгатенең барлыкка килүе һәм үсеше, иң беренче чиратта, ижтимагый хезмәт бүленешенә бәйле. Әүвәл һөнәрчелек игенчелектән аерылып чыга. Шуның нәтиҗәсендә сәүдә-һөнәрчелек үзәкләре, шәһәрләр барлыкка килә. “Борынгылыкта теге яки бу халыкта язу куллана башлау, - ди Х.Госман, - аның сәүдә-һөнәр шәһәрләре, шәһәр тормышы барлыкка килү белән бәйләнгән.” [2, 6]. Ә инде хезмәт бүленешенең иң югары баскычы – физик акыл хезмәтләре арасында бүленеш.

Х.Госман Идел-йортта Болгар һәм Алтын Урда чорларында ук күпләгән шәһәрләрнең булуын, утрак тормышның алга китешен, физик һәм рухи хезмәт бүленешенең киң таралышын искәртә һәм шул нигездә язма әдәбиятның да элек-электән татарда көчле икәнлеген ассызыклый. Бу концепция галим карашларының ныклы теоретик һәм методологик нигезен тәшкил итә.

Мәгълүм сәбәпләр аркасында татарның язма истәлекләре үз вакытында тиешенчә тупланмаган, өйрәнелмәгән. Бу ачы хакыйкатьне тирәнтеп аңлап, Х. Госман элеккеге ядкярләрне эзләүгә, тупларга һәм гыйльми тикшерүгә җитди игътибар итте. Аның җитәкчелегендә, турыдан-туры катнашлыгында төрле фәнни экспедицияләр оештырылды, меңәрләгән язма истәлекләр

китапханәләрдә, архивларда тупланды. Мәшһүр Миркасыйм Госмановның археограф булып китүендә дә остазы Х. Госманның роле зур булды.

Х.Госман Урта гасыр сүз сәнгатенең күп кенә ядкярләрен текстологик яктан тикшереп, гыйльми җәмәгатьчелеккә җиткерүдә күп эшләр башкарды. Мәсәлән, ул Алтын Урда чоры шагыйре Хисам Кятибнең “Җөмҗөмә солтан” әсәрен (1369) тиешле шәрех-аңлатмалар, бай эчтәлекле кереш мәкалә белән 1970 елда бастырып чыгарды [3]. Шунысы мөһим: биредә галим Х.Кятиб әсәренең берничә кулъязмасын, басма пөсхәсен файдаланып, тәнкыйди-җыйнама текстын төзи.

Алтын Урда шагыйре Котбның фәнни әйләнешкә кереп китүе дә, нигездә, Х.Госман эшчәнлеге белән бәйле. Ул бу шагыйрь хакында берничә мәкалә язды. З.Максудова белән берлектә “Хөсрәү вә Ширин” әсәрен гарәп графикасында 1969 елда нәшер итте [4].

Х.Госман XIV йөз шагыйре Сәйф Сараи иҗатын өйрәнүгә, аеруча аның әсәрләрен укучыларга җиткерүгә зур өлеш кертте. Ул әүвәл бу авторның лирик әсәрләрен, нәзыйрә шигырьләрен 1966 елда аерым китапчык рәвешендә бастырды [5]. Шул ук елда аның “Казан утлары” журналында (12 нче сан. – 126-137 б.) С.Сараи иҗаты хакында язмасы дөнья күрде. 1980 елда “Китабе Гөлестан бит-төрки” кулъязмасындагы әсәрләр Казан университеты нәшриятында гарәп хәрефләре белән басылып чыкты. Бу китап Х.Госман, З. Максудова, Р. Кадыйров тарафыннан әзерләнгән иде. Шушы ук авторларның тәүге икесе 1967 елда моңа кадәр юньләп билгеле булмаган XVIII йөз шагыйрьләренең әсәрләрен фәнни әйләнешкә кертеп җибәрделәр [6].

Х. Госманның Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятын өйрәнү өлкәсендәге эшчәнлеге текстология белән генә чикләнми. Ул бу дәвер сүз сәнгатенең аерым мөһим проблемаларын да тикшерде. Галимнең “Древние истоки тюркского стиха” (КДУ нәшр., 1984. – 148 б.), “Тюркский стих в средние века” (КДУ нәшр., 1987. – 144 б.) монографияләре татар әдәбият фәнендә генә түгел, гомумән тюркологиядә җитди хезмәтләр рәвешендә кабул ителде. Аларда төрки-татар шигыренең нигезләре, Болгар, Алтын Урда чорларында

һәм аннан соңгы гасырларда нинди үсеш-үзгәрешләр алуы ныклы теоретик җирлектә, бай фактик материалга таянып яктартыла. Галимне X1X йөзгә кадәр сүз сәнгатенең идея-эстетик агышы, сәнгати хосусиятләре, үзеннән соңгы әдәбияттагы традицияләре дә кызыксындырды. Аның “Татар поэзиясе, тарихында Тукайның урыны” мәкаләсе [7, 233-250] – шуның күркәм бер үрнәге. Биредә бөек шагыйрьнең иҗаты татар сүз сәнгате үсешенең меңъеллык тарихы кысаларында карала, Урта гасыр әдәбиятның аерым үзенчәлекләре хакында мөһим фикерләр әйтелә.

Х.Госманның Урта гасырга мөнәсәбәтле күпчелек хезмәтләре иң беренче чиратта студентларга адресланган. Болар арасында “Борынгы төрки һәм татар әдәбиятының чыганаклары” әсбабы (1987) аеруча кыйммәтле [8]. Анда гомумитөрки әдәбияттан, Алтын Урда чоры шагыйрьләре иҗатыннан күп кенә үрнәкләр бирелә. Китапта авторлар һәм әсәрләр хакында кыскача белешмәләр, текстларга тиешле шәрех-аңлатмалар да бар. Бу басма инде менә өч дистә ел буена Урта гасыр әдәбиятыннан студентлар өчен ышанычлы әсбап булып хезмәт итә.

Х. Госман, гомумән, элеккеге мирасны камил белгән белгечләр тәрбияләүне һәрчак күз уңында тотып килде. Аның гыйльми җитәкчелегендә К.Дәүләтшин (Мәүла Колый иҗаты), Х.Миңнегулов (С.Сараиның иҗат мирасы), Ә. Шәрипов (Утыз Имәни) һәм башкалар кандидатлык диссертацияләре якладылар, җитди генә фәнни хезмәтләр тудырдылар.

Соңгы ярты гасырда Борынгы һәм Урта гасыр татар әдәбиятын өйрәнүдә җитди генә эшләр башкарылды, бу өлкәдә әдәбият фәне зур үсеш алды. Бу уңышларда профессор Хатип ага Госманның өлеше аеруча зур.

**Файдаланган әдәбият**


1. Миннегулов Х.Ю. Хатип Усманович Усманов. Изд.-во КГУ, 2002. – 20 с.
2. Борынгы төрки һәм татар әдәбиятының чыганаклары / Төзүче Хатип Госман. – Казан университеты нәшрияты, 1981. – 248 б.
3. Хисам Кятиб. Җөмҗөмә солтан / Басмага әзерләүче Х.Госман. – КДУ нәшр., 1970. – 110 б.
4. Котб. Хөсрәү-Ширин хикәяте. Ике кисәктә. – КДУ нәшр., 1969. – 441 б.
5. Татар әдәбият тарихыннан студентларының практик дәресләре өчен материал / Төзүче Х.Госман. – КДУ нәшр., 1966. – 25 б.
6. Татар әдәбияты тарихыннан студентларның практик дәресләре өчен уку материаллары / Төзүчеләре – Х. Госман, З. Максудова. – КДУ нәшр., 1967. – 99 б.
7. Слово О Тукае / Составитель Ф. Зулькарнаев. – Казан: Таткнигоиздат, 1986. – 431 с.
8. Без фәкыйрьсез бу китапның [2] редколлегия составында гына күрсәтелсә дә, аны әзерләүгә аның да зур өлеш керде.


III. 2011